**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**11.11.2022 ел** **№ 1064**

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау трында» 2022 елның 04 апрелендәге 391 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүгә, шул исәптән Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә муниципаль ярдәм итү, шәхси ярдәмче хуҗалыкларның тотрыклы эшләвен тәэмин итү һәм мөгезле эре терлекләрнең баш санын арттыру, базар икътисады һәм милек формаларының төрлелеге шартларында авыл халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү, шәхси ярдәмче хуҗалыклары ияләренең икътисадый мәнфәгатьләрен яклау исәбенә аларның керемнәрен арттыру максатларында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау трында» 2022 елның 04 апрелендәге 391 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның бөтен тексты буенча «муниципаль максатчан программа» сүзләрен «муниципаль программа» сүзләренә тиешле килешләрдә алмаштырырга;

1.2. «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» карар атамасын «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. программа паспортындагы «Программаны эшләү өчен нигез» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| **Программаны эшләү өчен нигез** | Халыкның ШЯХ ларын хокукый җайга салу түбәндәге норматив актлар нигезендә гамәлгә ашырыла:<br>-Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе;<br>- Россия Федерациясе Гражданнар кодексы;<br>-«Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- «Россия Федерациясендә кулланучылар |

| | |
|---|---|
| | кооперациясе (кулланучылар җәмгыятьләре, аларның берлекләре) турында» 1992 елның 19 июнендәге 3085-1 номерлы Федераль закон;<br>- «Авыл хуҗалыгы кооперациясе турында» 1995 елның 8 декабрендәге 193-ФЗ номерлы Федераль закон.<br>- «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон.<br>- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 елның 31 маендагы 397 номерлы карары |

1.4. программа паспортындагы «Финанслау чыганаклары» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="7">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="2">Программаны финанслау күләме бюджетның өстәмә керемнәре һәм (яисә) Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларының калган өлешләре исәбеннән 9 000,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:</td></tr>
<tr><td>2022 ел</td><td>3000,0 мең сум</td></tr>
<tr><td>2023 ел</td><td>3000,0 мең сум</td></tr>
<tr><td>2024 ел</td><td>3000,0 мең сум</td></tr>
<tr><td colspan="2">Программа буенча гомуми лимитны елына 3000,0 мең сум күләмендә расларга.<br>Искәрмә: финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм, Биектау муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, төзәтмәләр кертелергә тиеш.</td></tr>
</table>

1.5. программа паспортындагы «Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| **Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре** | Программаны тормышка ашырудан социаль-икътисади нәтиҗәлелек түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>- шәхси ярдәмче хуҗалыкларда җитештерү эшчәнлеген үстерүдән;<br>- район авылларында яшәүчеләрнең нормаль көн күрүе өчен шартлар булдырудан; |

| | |
|---|---|
| | - шәхси ярдәмче хуҗалыкларның (ШЯХ) тотрыклы эшләвен тәэмин итүдән;<br>- 2022 елда субсидияләр рәвешендә ярдәм алган гражданнарга эре мөгезле терлекләрнең баш санын арттыру исәбенә керемнәрне кимендә 2%ка арттырудан;<br>- базар икътисады һәм милек формаларының күптөрлелеге шартларында авыл халкының тормыш-көнкүреш дәрәҗәсен күтәрүдән;<br>- шәхси ярдәмче хуҗалыклар ияләренең (физик затларның) икътисадый мәнфәгатьләрен яклаудан. |

1.6. программа паспортындагы «Программа чараларына контроль системасы» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| **Программа чараларына контроль системасы** | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты |

1.7. программадан 5.1, 5.2, 6 бүлекләрне һәм 1, 2 нче кушымталарны төшереп калдырырга;

1.8. 5 бүлек түбәндәге абзацларны өстәргә өстәргә:

«Программаны үтәү критерийлары Программа чаралары шәхси ярдәмче хуҗалыкларда җитештерү эшчәнлеген үстерүне тәэмин итәргә һәм районның авыл халкының нормаль тормышы өчен шартлар тудырырга мөмкинлек бирәчәк. Программаны үтәү критерие булып, 2022 елда субсидияләр рәвешендә ярдәм алган гражданнарга эре мөгезле терлекләрнең баш санын арттыру исәбенә керемнәрне кимендә 2%ка арттыру тора.

Район башкарма комитеты һәм район Контроль-хисап палатасы бюджет акчаларыннан максатчан файдалануны тикшереп тора һәм Программаның нәтиҗәлелегенә аудит үткәрә. Максатчан файдаланмау фактлары ачыклаганда, субсидия алучы бюджет акчаларын кире кайтарырга тиеш. Программаның чараларын гамәлгә ашыру барышы һәм нәтиҗәләре турында һәр яртыеллыкта район башкарма комитетында авыл җирлекләре башлыклары катнашында фикер алышулар үткәрелә. Программаны гамәлгә ашыру турында хисап Биектау муниципаль районы башкарма комитетының икътисад бүлеге тарафыннан Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә ел саен тапшырыла»

2. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 04 апрелендәге 391 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 02 июнендәге 556 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http//vysokaya-gora/tatarstan.ru веб-адрес

буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин